ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

______________ с. Верхний Услон ______________

Татарстан Республикасының Югары Ослан муниципаль районында конкуренция үсешенә ярдәм итү буенча «Чаралар планын («Юл картасын») раслау турында» 2022 елның 15 сентябрендәге 997 номерлы Башкарма комитет карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 02.09.2021 №2424-р күрсәтмәсе белән расланган 2021-2025 елларга Россия Федерациясендә конкуренцияне үстерү милли планын («Юл картасын») гамәлгә ашыру, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы территориясендә конкуренцияне үстерү шартларын тудыру максатларында, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында конкуренция үсешенә ярдәм итү буенча чаралар планын («Юл картасын») раслау турындагы» 15.09.2022 ел №997 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында конкуренция үсешенә ярдәм итү буенча чаралар планын («Юл картасы») яңа редакциядә кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-икътисадый үсеш буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы А.А.Ахметшин

Әзерләде һәм бастырды
Т.Г.Архиреева

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитетының
________ №_______ карарына
Кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында 2022-2025 елларга конкуренция үсешенә ярдәм итү буенча
«Юл картасы»

| № т/б | Мәсьәләне үтәү өчен чара исеме | Максатчан индикаторлар | Үлчәү берәмлеге | Максатчан индикатор бәяләмәсе (конкуренция үсешенең төп күрсәткечләре) | | | | Максатчан индикаторны исәпләү методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 1. Балаларга өстәмә белем бирү хезмәтләре базары | | | | | | | | | |
| 1.1 | Иртә үсеш төркемнәрен һәм мәктәпләрен булдыру. Мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балалар өчен түләүле нигездә кирәкле юнәлешләр буенча өстәмә белем бирү мәктәп берләшмәләрен ачу. | Өстәмә белем бирү өлкәсендә түләүле хезмәтләрдән файдаланучы мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балалар өлеше. | % | 26 | 28 | 30 | 31 | Өстәмә белем бирү өлкәсендә түләүле хезмәтләрдән файдаланучы мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балалар саны/ район буенча мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге гомуми саны*100 | «Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ, «Югары Ослан муниципаль районы мәдәният бүлеге» МКУ |
| 2. Хуҗалык итүче субъектларның товар базарларына ташламалы керүе өчен шартлар тудыру | | | | | | | | | |
| 2.1 | Муниципаль унитар предприятиеләр санын | Ликвидацияләнгән/үзгәртеп оештырылган муниципаль | берәмлекләр | - | - | 3 | - | Исәп-хисап ясау методикасы таләп ителми | Югары Ослан муниципаль районы Башкарма |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | район территориясендә кыскарту | унитар предприятиеләр саны | | | | | | | комитеты, “Югары Ослан муниципаль районы милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы” МКУ |
| 3. Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары товарларының, эшләренең, хезмәтләренең конкурентлыкка сәләтен үстерү | | | | | | | | | |
| 3.1 | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларыннан сатып алулар күләме арту | Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арасыннан тәэмин итүчеләр санын һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары төзи торган шартнамәләр санын арттыру | % | Кимендә 30 | Кимендә 30 | Кимендә 30 | Кимендә 30 | Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары төзи торган шартнамәләр саны * 100 шартнамәләрнең гомуми саны | ТР Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты |